**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 27.04.2020

КАРАР
№ ПР-81

**«Район хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү турында»**

Актаныш муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында карар бирәм:

1. Хәрби комиссариатка (Актаныш муниципаль районы) район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният һәм агарту эшләре бүлеге белән берлектә, 2020 елның 15 маенда хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрүне оештырырга. 1 нче кушымта нигезендә, район хәрби хезмәткә чакырылучы көнен үткәрү планын расларга.
2. Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына 2020 елның 15 маенда чараны үткәрү урынына хәрби хезмәткә чакырылучыларны һәм аларның ата-аналарын килүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына хәрби комиссариатка (Актаныш муниципаль районы) 2 нче кушымта нигезендә, 2020 елның язында хәрби хезмәткә чакырылучыларга бүләкләр алу өчен 5810.00 сум күләмендә акча бүлеп бирүне карарга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына 1 нче кушымта
27.04 2020 ел № ПР-81

**Хәрби хезмәткә чакырылучыларның район көнен үткәрү**
**ПЛАНЫ**

| № т/б | Чаралар исеме | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Үткәрү урыны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Хәрби хезмәткә чакырылучыларны һәм аларның ата-аналарына хәбәр итү һәм җыю | 9:00 15.05.2020 ел | Актаныш районы хәрби комиссариаты, авыл җирлекләре башлыклары | "Яшьлек" милли-мәдәни үзәге янындагы мәйдан |
| 2 | Җыелу | | | |
| | хәрби хезмәткә чакырылуга һәм хәрби хезмәт үтүгә бәйле РФ, ТР Конституциясе статьяларын җиткерү буенча чакырылыш комиссиясе рәисе чыгышы; | 9:00 – 9:15 | чакырылыш комиссиясе рәисе | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| | «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында" РФ законын аңлату белән ТР хәрби комиссариат бүлеге башлыгы чыгышы; | 9:15 – 9:30 | Актаныш районының хәрби комиссары | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| | "Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның җаваплылыгы" темасына район прокуроры чыгышы; | 9:30 – 9:45 | район прокуроры | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| | Хәрби хезмәткә чакырылу контингентының сәламәтлеге торышы мәсьәләсе буенча өлкән табибның чыгышы; | 9:45 – 10:00 | өлкән табиб | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Бөек Ватан сугышында катнашучылар, сугышчы-интернационалистларның чыгышлары һәм башкалар | 10:00 – 10:15 | | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| | Армиягә чакырылучыларның һәм аларның ата-аналарының теләкләре | 10:15 – 10:30 | | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| | Катнашучыларда барлыкка килгән сорауларны ачыклау | 10:30 – 10:45 | | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| 3 | Үзешчән сәнгать концерты | 10:45 – 11:15 | мәдәният бүлеге мөдире | «Яшьлек» милли-мәдәни үзәге |
| 4 | Тәнәфес | 11:15 – 11:30 | | |
| 5 | Бүләкләр тапшыру белән спорт ярышлары | 11: 30 | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы | Балалар иҗат йорты |

* Искәрмә: Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә буйсынмаган җаваплы затлар хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү планына килешү буенча кертелә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына 2 нче кушымта
27.04 2020 ел № ПР-81

**ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ ЧАКЫРЫЛУЧЫЛАР КӨНЕН ҮТКӘРҮГӘ ЧЫГЫМНАР СМЕТАСЫ**

| № т/б | Чыгымнарның атамасы | Сумма |
|---|---|---|
| **1** | Приз фонды(ату, йөгерү, гер күтәрү, күтәрелү, АКМ җыю)<br>1 урын-300 сум х 5 кеше - 1.500 сум<br>2 урын-250 сум х 5 кеше - 1.250 сум<br>3 урын-200 сум х 5 кеше - 1.000 сум | 3750 сум |
| **2** | Грамоталар-10 сум х 18 кеше-180 сум | 180 сум |
| **3** | Блокнот һәм ручка 40 сум х 47 кеше = 1880 сум | 1880 сум |
| **4** | **БАРЫСЫ:** | **5810 сум** |